| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯҢГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**КАРАР**

23 июнь 2020 ел № 128

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларың 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча «Хезмәт» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга.

Яңгул авыл җирлеге
башлыгы Р.Ф.Габдрахманов

М.У.